Бүгенге санда:  **Нурлатта быел 15 йортны капремонт көтә.** 2 бит.


# Дуслык
Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 21 гыйнвар 2015 ел

№ 3 (10532)


**22 гыйнварга һава торышы:** болытлы һава; урыны белән кар; җил төньяк-көнчыгыштан, 3-4 м/с; температура көндез -12°С, төнлә -15°С

## *Абзац-информ*

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

### ҖӘМӘГАТЬ ТЫҢЛАУЛАРЫ ҮТТЕ

Кичә район Советында Нурлат районы башлыгы урынбасары Флюра Ногманова рәислегендә район һәм шәһәр Уставларына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектларын карау буенча җәмәгать тыңлаулары үтте. Алар белән район Советы юристы Александр Ханеня таныштырды һәм Уставларны кабул итү тәртибен аңлатты. Тыңлаучылардан тәкъдимнәр һәм замечаниеләр кермәде. Җәмәгать тыңлаулары үтте дип танылды.

### ТӘРТИПЛЕЛӘР АРТА

Балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиянең узган атнада үткән утырышында тәртипләрен яхшырткан 4 гаилә һәм 4 яшүсмер исәптән төшерелгән. Утырышта барлыгы 16 материал каралган.

### МӘГАРИФТӘ – ТИКШЕРҮ

19-20 гыйнварда районның мәгариф һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә Рособрнадзор белгечләре эшләде. Белгечләр өстәмә белем бирү хезмәтләрен тәкъдим итүдә граждан нарның хокуклары яклануга аерата игътибар бирделәр.

### МӘДӘНИЯТ ХИСАП ТОТА

Сишәмбедән район мәдәният учреждениеләрендә хисап концертлары башланды. 6 февральгә кадәр районның 50 мәдәни учагында концертлар узачак.

### БЕЛЕМНЕ ОЛИМПИАДА КҮРСӘТӘ

1 мартка кадәр район турында җыңү яулаган 83 укучы ике дистәгә якын фән буенча олимпиадаларның республика турында үз көчен сынаячак. Интеллектуаль ярышларда катнашучы укучылар өчен мәдәни программа да каралган, ә педагоглар өчен семинар-киңәшмәләр уза.

# Алдан кайгырткан - откан

## Георгий Степанов белән Николай Матюшкин техника язгы чәчүдә сынатырлык булмасын дип эшлиләр



Л.Мөбарәкшина фотосы

**Урамда әле калын кар ята, ә "Агромир" җәмгыятендә чәчү кампаниясенә әзерлек инде азагына якынлашып килә.**

- Быел машина-трактор паркыбыз бер дә ябылып тормады дияргә була, - дип эшләрнең оештырылуы белән таныштыра өлкән диспетчер Илья Крючков. – Механизаторлар да кышын ялга китмәде, бар да эш белән мәшгуль булды. Бездә техника нигездә үзебез илнеке, запчастьлар белән дә проблемалар юк.

Узган атна азагында бүлекчә базасында үткәрелгән район семинарында катнашучыларны да Егоркиноның машина-трактор паркы зур җанлылык белән каршы алды. Әнә, механизаторлар Николай Матюшкин белән Георгий Степанов культиватор ремонтлау белән мәшгуль. Кая шөребен ныгытасы, кая алмаштырасы бар - һәр детальне энә күзеннән диярлек үткәрәләр, кырга чыккач сынатмаслык булсын, дип эшлиләр егетләр. Ремонт барышында исә һәркайсына слесарь да, механик та булып алырга туры килә, ә эретеп-ябыштыру эшләре нигездә Олег Матвеев өстендә. Оста механизаторлар кулы аша узган әзер чәчү техникасы исә парк территориясендә тезелә бара.

Җәмгыятьнең генераль директоры Дмитрий Понин әйтүенчә, чәчүгә чыгачак техниканың 80 процентлабы әзер икән инде, февраль уртасына ремонтны тулысынча төгәлләргә дигән ниятләре дә юк түгел, чәчү башланганчы техника паркын яңарту өстендә дә эшләячәкләр икән.

*(Ахыры 2нче биттә)*

КӨН КАДАГЫНДА

# Легаль хезмәт хакы тотрыклылыкка өметләндерә

**Республикада бюджеттан тыш предприятиеләрдә хезмәт итүчеләр өчен минималь хезмәт хакы 6420 сум тәшкил итә. Әмма эш бирүчеләр хезмәткәрнең "ак" хезмәт хакы турындагы мәгълүматларны рәсми рәвештә азайтып күрсәткән очраклар да бар.**

Әле узган елда ук Профсоюзлар федерациясе, эш бирүчеләр берләшмәләре Координацион советы һәм ТР Министрлар Кабинеты икътисадның бюджеттан тыш секторында минималь хезмәт хакы турында килешү төзеделәр. Эшмәкәрләргә бу хакта узган атнада Нурлат районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча комиссия утырышында кабат искәрттеләр. Ул район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Руслан Морадыймов катнашында үтте.

Комиссия әгъзалары әйтүенчә, утырыш күбрәк профилактик төсмердә оештырылган. Утырышка чакырылган эшмәкәрләргә кыска вакытларда район башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә һәр хезмәткәргә өстәмә килешү төзеп китерергә киңәш ителде. Бу эш бирүчеләр һәр хезмәткәр өчен салым инспекциясенә, Пенсия фондына кертемнәрне вакытында рәсми күчереп барсыннар, иминият кертемнәрен күчерсеннәр өчен эшләнә.

– Килешү маддәләре нигезендә, бюджеттан тыш секторда эшләүченең айлык хезмәт хакы компенсацион һәм стимуллаштыручы түләүләрне дә кертеп, 6420 сумнан да ким булмаска тиеш, - ди халыкның мәшгульлеге үзәге директоры Лилия Шакирова. – Эш бирүчеләрнең хезмәт законнарын үтәвенә дәүләти күзәтчелекне федераль хезмәт инспекциясе алып бара. Әлеге законны үтәмәгән өчен эш бирүче административ җаваплылыкка тартылырга мөмкин. Хезмәт хакы 6420 сумнан кимрәк булганда, хезмәткәр үзе дә республиканың хезмәт инспекциясенә, судка, прокуратурага мөрәҗәгать итә ала.

Комиссия утырышында хезмәткәрләрне сынау срогы белән дөрес рәсмиләштермәү фактлары булуы да әйтелде. Мәсәлән, ТРның кече һәм урта эшмәкәрлек предприятиеләре ассоциациясе вәкиллеге җитәкчесе Халидә Әбделманова еллар буе "сынау срогы" белән эшләп йөргән очраклар да бар, дип билгеләп үтте. Биредә мондый күренешләрне ачыклау максатыннан тикшерүләр үткәрергә кирәк, дип тәкъдим ителде.

Бу юлы комиссия утырышына эшмәкәрләр генә чакырылган иде. Шундый ук эш авыл хуҗалыгы һәм башка бюджеттан тыш предприятиеләр җитәкчеләре белән дә дәвам иттереләчәк.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

САН

**55**

**– кичәге көнгә әнә шулкадәр хезмәт шартнамәсе һәм өстәмә килешү төзелгән.**

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

## Алдан кайгырткан - откан

*(Ахыры. Башы 1нче биттә)*

Ә менә район буенча әзерлек әле 20 процентлап кына тәшкил итә. Күп хуҗалыкларның экономия максатыннан кышын машина-трактор паркларын эшләтми торуыннан да бу. Әмма бу очракта эшне соңракка калдыручылар оттырмадылармы икән әле? Әнә, ел башыннан инде запас частьлар, техникага бәяләр артырга да өлгерде. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан быел язгы чәчү кампаниясе узган елгыга караганда 4 млрд. сумга кыйммәтрәккә төшәчәк, дип белдерделәр. Бу нигездә чит ил техникасына запас частьлар, орлык һәм ашламаларның бәясе артуы белән бәйле.

- Бездә чәчүгә 300дән артыграк трактор чыгачак, шуларның 54е – чит илнеке, - ди авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе консультанты Вәгыйзь Сатдаров. – Чит ил техникасына запчастьларны инде быелдан республиканың үз заводларында җитештерә башлау турында да сүз бара. Хуҗалыклар буенча запчастьларга заявкалар җыелды инде, эш җайга салынса, чыгымнар күпкә азрак булыр иде, әлбәттә.

Ел аграрчылар алдына әнә шундый проблемалар куйса да, кыр эшләрендә тоткарлык булмаска тиеш. Шуңа да районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин авыл хуҗалыгы машиналары ремонтын 1нче, ә тракторларныкын 25нче мартка төгәлләргә дип, бурычларны конкрет куйды. 1 апрельдән инде хуҗалыкларның язгы чәчүгә әзерлеген республика комиссиясе тикшерәчәк.

Бу көнне район семинарында катнашучылар исә "Агромир"ның шул бүлекчәдәге терлекчелек фермаларында да булдылар, хуҗалыкта терлекләрне ашатуда яңа технологияләр куллана башлаулары исә һәркайсында зур кызыксыну уятты. Егоркино бүлекчәсе фермаларында быел терлекләрнең рационына көнбагыш түбе һәм катлаулы углеводлар кертеп, тәүлеклек савымны бермәбер арттыруга ирешкәннәр. Биредә үк тулаем район буенча терлекчелек тармагына еллык йомгак ясалды, яңа максатлар билгеләнде. Семинар эшендә катнашкан район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин һәр ике юнәлеш буенча да эшләрне тиешле дәрәҗәдә оештырырга дигән бурыч куйды.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

КАПРЕМОНТ-2015




МЕДВЕДСКИЙ УР., 2ДӘГЕ ЙОРТНЫ ЖЫЛЫТУ ҺӘМ ТЫШЛАУ ИЮНЬГӘ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН

## Эшләр этаплап алып барыла

**Быел шәһәрдә капиталь ремонт программасы буенча эшләр 15 йортта алып барылачак.**

– Намуслы эшлиләр, мәшәкатьләр тудырмыйлар, – ди шикәрчеләр микрорайонындагы Медведский ур., 2нче йортында яшәүче бер ханым, безнең йорт түбәсен күзәтүебезне сизеп. Танышып киттек. Анна Яфонкина ике-өч сүз белән йортның тарихын сөйләп алды.

Ул 1980 елда төзелгән. Шул 34 ел эчендә беренче тапкыр капиталь ремонт кичерә. Бу эш белән "Новый дом" подряд оешмасы шөгыльләнә.

Түбә эшләрен әле күптән түгел генә башлаган булганнар, ә инде февраль уртасынарак подрядчылар эшне төгәлләргә планлаштыра. Чөнки эшнең бер өлешен әле көзен үк башкарып куярга өлгергәннәр. Мисал өчен, ул чагында җилләткеч каналларны тулысынча корып бетергәннәр. Хәзер 6 кеше иске шиферны сүтә, яңа бәпкәләр кора, аны профкалай белән ябачаклар. Ә бу атнада сантехника һәм электрикага тотынмакчылар.

– Шул көннәрдә сантехника кайтырга тиеш, кирәкле торбалар бар инде, – диде прораб. – Бөтен кирәкле материал кулда булмыйча, без санузелларны алыштыру эшен башлый алмыйбыз. Аларны алып кайтуга ук демонтаж һәм монтаж ясаячакбыз. Электр щитлары белән дә шулай. Материал бу атнада булыр дип исәп тотабыз. Электр исәпләгечләрен фатирлардан подъездларга чыгарырга ниятлибез. Бу электр буенча зур ОДНнардан котылырга ярдәм итәр дип уйлыйбыз.

"Новый дом" подряд оешмасы капиталь ремонт белән 2008 елдан бирле шөгыльләнә. Прораб Николай Семенов әйтүенчә, ачыкланган барлык җитешсезлекләрне дә алар объектны тапшырганчы, тиз арада хәл итәчәкләр икән.

– Кешеләр өчен ясыйбыз бит, ә алар безнең эштән канәгать калырга тиеш, – ди ул. Бу подрядчы оешма өч йортта капиталь ремонт белән шөгыльләнә. Берүк вакытта Завод ур., 3тә дә эшлиләр. Анда суүткәрү һәм канализация эшләрен төгәлләгәннәр инде. Материаллар тулысынча кайтып җиткәч, подъезддагы электр үткәргечләрен алыштыра башлаячаклар. Бу йортның башкалардан шактый аерымлыгы бар, биредә баскычлар агачтан. Шул гомер эчендә алар ярыйсы ук чалшаерга өлгергәннәр. Николай Семенов әйтүенчә, аларын да алыштырачаклар икән.

– Бу йортта ремонт эшләренә подъездлардагы агач идәннәрне һәм баскыч маршларын алыштыру да кертелгән, – диде ул. Йортның түбәсен 8 ел элек алыштырган булганнар, һәм бу юлы бу төр эш каралмаган, ди прораб. Әмма аннан башка да эшләр күп. Суүткәргеч, канализация, электрдан тыш, фасадны җылыту һәм тышлау, яңа отмосткалар ясау, подъезд тәрәзәләрен һәм ишекләрен алыштыру каралган.

Йортта яшәүчеләр подрядчылар белән уртак тел тапкан, алар да фатир хуҗаларын кырыс контролерлар буларак кабул итә алган, тик менә коммуналь службаларны гына аңлап бетерә алмыйлар. Эш шунда, бер айлап инде биредәге йорт ишегалдында киселгән агачлар аунап ята.

– Башта иске тупылларны кистерә алмый интектек, – ди шул йортта яшәүче Татьяна Фролова. – Бары тик район башлыгына мөрәҗәгать иткәч кенә, Яңа ел алдыннан агачларны кистеләр, әмма бүгенгә кадәр алар шунда ята.

Йорт тирәсе гадәттән тыш хәл килеп туса да куркыныч тудырырлык, подрядчыларга да бик үк җайлы түгел. Бәлкем, башлаган эшне хакимиятнең катнашыннан башка да азагына җиткерергә өйрәнергә вакыттыр инде. Югыйсә, берәүләр йортта яшәүчеләрнең шартларын яхшыртырга тырыша, ә башкаларны моның өчен үз вазифаларын үтәргә мәҗбүр итәргә туры килә бит.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

### ХӘБӘРЛӘР

#### НУРЛАТ ПРОДУКЦИЯСЕ МӘСКӘҮНЕ КЫЗЫКТЫРГАН

**Узган атна азагында Казанның агросәнәгать паркында үткән сөт продукциясе һәм аны дегустацияләү күргәзмәсендә "Нурлат сөте" җәмгыятенең сөт заводы да катнашты һәм үз продукциясен тәкъдим итте.**

Завод белгечләре әйтүенчә, Татарстанның азык-төлек базарын үстерү, җирле җитештерүчеләрнең югары сыйфатлы продукциясен сату өлкәсен киңәйтү һәм халык арасында популярлыгын арттыру максатыннан уздырылган күргәзмә "Татарстанныкын сатып ал!" шигаре астында узган. Һәм анда "Нурлат сөте"нең сөт һәм сөт продукциясенең сыйфаты һәм ассортименты казанлылар һәм башкала кунакларында зур кызыксыну уяткан. Атна башыннан Нурлат сөт заводына Мәскәүнең бер компаниясеннән продукцияне күпләп сатып алу тәкъдиме белән чыгулары да шул хакта сөйли.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

#### ЯКТАШЫБЫЗ – РЕСПУБЛИКА СӘХНӘЛӘРЕНДӘ

**Якташыбыз, җырчы Рузалия Гомәрова күңелле мәшәкатьләр белән яши бу көннәрдә.**

– Иң бәхетле көннәрем, дисәм дә ялгыш булмас, - ди ул үзе. – Узган ел азагыннан башлап концерт турын алып барам. Башта район авылларында тамашачыларга концертлар тәкъдим итсәм, хәзер республикабыз шәһәрләре сәхнәләренә дә чыктым. Чистайда концерт аншлаг белән узды. Алда Әлмәт, Балык Бистәсендә һәм язга Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясендә чыгыш ясарга планлаштырам. Концерт туры программасында "Җәләл" төркеме, Айдар Мусин, Гөлнара Мәүлетова чыгышлары да бар.

Җырчы-якташыбыз иҗат дөньясы белән генә чикләнми, югары белем алуны да параллель рәвештә алып бара икән. Моңа кадәр театр училищесын тәмамлаган Рузалия Гомәрова икенче белгечлек – психолог һөнәрен үзләштерә.

#### "СЕРДӘШ" – ХӘЙРИЯ ЮЛЫНДА

ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Сәмигулла Рәхмәтуллин җитәкчелегендәге "Сердәш" ансамбле бу атнада хәйрия концертлары турын башлап җибәрә. Коллектив Якты Күл һәм Биккол авылы тамашачыларына концерт программасын бүләк итәчәк.

**Зилия ӘКСАНОВА**

### РӘСМИ

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРАРЫ**

25 декабрь 2014 ел №1296

**2015 елга Нурлат муниципаль районында мәетләр җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге тарифларын раслау турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон, "Күмү һәм җирләү эшләре турында"гы 1996 елның 12 гыйнварендагы №8-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы "Күмү һәм җирләү эшләре турында"гы Федераль законны Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары турында"гы №196 карары нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районында мәетләр җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге тарифларын расларга һәм 2015 елның 1 гыйнвареннан гамәлгә кертергә (1нче кушымта).
2. Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 30 декабрендәге "2014 елга Нурлат муниципаль районында мәетләр җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә тарифларны раслау турында"гы №1245 карарын үз көчен югалткан дип санарга.
3. Карарны "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасында бастырырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.
4. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары Р.З.Сингатуллинага йөкләргә.

**ТРның Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К.Габдуллин.**

**1нче кушымта**
**Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 25 декабрендәге №1296 карары белән расланган.**

**Нурлат муниципаль районында мәетләр җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге ТАРИФЛАРЫ**

| Критерийлар атамасы | Хезмәтләр бәясе, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Тариф, шул исәптән | 5277,28 |
| -җирләү өчен кирәкле документлар ясату; | 110,77 |
| -ритуаль кирәк-яраклар (христиан йоласы өчен киемнәр комплекты, мөселман йоласы өчен кәфенлек); | 1685,98 |
| -мөселманча җирләү өчен такталар, христианнарга табутлар бирү һәм китерү; | 1770,40 |
| -мәетне (җәсәдне) зиратка илтү; | 609,26 |
| -җирләү (кабер казу һәм күмү). | 1100,87 |

### КАБУЛ ИТҮЛӘР

**23 гыйнварда,** 14.00да Совет ур., 100 адресы буенча ТР Дәүләт Советы депутаты **Илгиз Мисбах улы САЛИХОВ** халыкны кабул итә.

Алдан язылу һәм мәгълүмат өчен тел.: 92-3-19, 92-0-63.

***

**2015 елның 23 гыйнварендa** Татарстан Республикасы эчке эшләр министры урынбасары **Дамир Равил улы ДИННИУЛОВ** видеоконференция режимында халыкны кабул итә. Гаризалар тәүлек әйләнәсе Россия МВДсының Нурлат районы бүлегенең кизү частенда кабул ителә. Язылу өчен 22 гыйнварга кадәр Россия МВДсы Нурлат районы бүлегенең кабул итү бүлмәсенә мөрәҗәгать итәргә.

**Адрес: Нурлат ур., 7, тел.: 2-11-25.**

# ВӘЗГЫЯТЬ

“НУРЛАТНЕФТЬ” НГДУсында

# Уңыш нигезе – экономиядә

**Кризис һәм финанс тотрыксызлыгына да карамастан, нефтьчеләр уңышларга ирешеп тора. Бу хакта “Нурлатнефть” НГДУсының эш нәтиҗәләренә күз салсак та аңларга була. Чөнки алар еллык планны 100 процентка үтәп чыкканнар.**



КОМАНДАДА ЭШЛИ БЕЛҮ – ИҢ ЗУР ӨСТЕНЛЕК

“Нурлатнефть” НГДУсы начальнигы Илгиз Салихов та 2014 елны үзенчәлекле дип атады.

– Ул ел безнең көчле якларыбызны да ачты һәмниләр өстендә эшләргә кирәклеген дә күрсәтте, – диде ул үзенең докладында саннар белән таныштырып. – 1 һәм 3нче приказларның барлык күрсәткечләре дә үтәлде, ресурсларны тоту һәм эксплуатация чыгымнарының лимиты артып китмәде. Предприятие барлык чыганаклардан да 2353,8 мең тонна нефть чыгарды, бу 2013 елгы дәрәҗәгә карата 104,7 процент тәшкил итте.

Хисап елында Ашалчы чыганагыннан да узган елгыдан 91,3 мең тоннага күбрәк югары үзлелектәге нефть чыгарылган (236,9 мең тонна), ә бу чыганакны эшкәртә башлаганнан бирле әлеге күрсәткеч 656,7 мең тонна булган. Бирелә декабрь азагына тәүлеклек нефть чыгару 750 тоннага җиткән. Бу чыганакта 20 яңа скважина эшкә кертелгән, алардан 52,5 мең тонна югары үзлелектәге нефть чыгарылган. Алар буенча нефтьнең уртача дебиты тәүлегенә пландагы 9,4 тонна урынына 11,5 тонна тәшкил иткән. 40 скважина пар суырту өчен сафка кертелгән, аларның 11е пар кудырудан нефть чыгару категориясенә күчерелгән. Докладчы геология-техник чараларга да тукталды: эксплуатациягә план буенча 26 урынына 31 скважина кертелгән. Өстәмә нефть чыгару 68,1 мең тонна тәшкил иткән, шуның 18,3 мең тоннасы планнан тыш алынган. Нефть бирүчәнлекне арттыруның гидродинамик ысуллары да билгеләп үтелде, аның бәрабәренә нефть чыгару 279 мең тонна, ә өченчел ысуллар хисабына 718 мең тонна тәшкил иткән (планга карата 110,8 процент).

Катлам басымын тоту уңаеннан Илгиз Мисбахович өзеклекләрнең сизелерлек азаюын ассызыклады. Скважиналар фонды өстендә эшләү җәһәтеннән предприятие җитәкчесе ремонтта кулланылучы яңа технологияләрне билгеләп үтте.

Социаль әһәмиятле мәсьәләләр дә җитәкчелекнең күз угында. Мәсәлән, 45 фатирлы йорт төзү эше дәвам итә (агымдагы елның июлендә тапшырырга ниятлиләр). Тулаем 2005 елдан бирле “Татнефть” ААҖ көче белән ипотека төзелеше буенча 23 йорт корылган.

– Хезмәткәрләрнең тормыш дәрәҗәсе үсү, эш һәм көнкүреш шартлары яхшыру, спорт, ял итү, кадрларның квалификациясен күтәрү, яшь хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру – болар барысы да һәрчак компаниянең игътибар үзәгендә тора, – дип билгеләп үтте Илгиз Мисбахович. – 2014 елда хезмәткәрләрнең айлык уртача хезмәт хаклары – 18, эшчеләрнең 19,3 процентка үсте.

Предприятие җитәкчелеге производствога рационализаторлык идеяләрен кертүгә дә аерым игътибар бирә. Мәсәлән, 2014 елда 383 автордан 976 рационализаторлык тәкъдиме кертелгән. Алардан икътисади нәтиҗә 289,4 млн. сум тәшкил иткән (2013 елгыдан 26,5 млн. сумга артыграк), уйлап табуга 17 патент алынган. Коллектив Сакчыл производство коралларын да актив эшкә кертеп тора. Предприятие белгечләре 120дән артыграк проект керткән, моннан 13,5 млн. сум икътисади нәтиҗә алынган. Моннан тыш, НГДУ ел саен чыгарылучы нефть күләмен арттырып тора һәм “Татнефть” ААҖ производство төркеме предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча программаларны үтәүдә алдынгы позицияләрне били. 2014 елда программа 2,8 процентка арттырып үтәлгән.

НГДУ коллективы 2014 елда бик күп мөһим һәм әһәмиятле вакыйгалар кичерде. 50нче млн. тонна нефть чыгарудан тыш; “Нурлатнефть” чираттагы тапкыр “Архимед-2014” уйлап табулар һәм инновацион технологияләрнең Мәскәү XVII Халыкара Салонында катнашты. Халыкара жюри карары белән НГДУның уйлап табулары 2шәр алтын һәм көмеш, 1 бронза медальгә лаек булды. Нефтьчеләрнең спорт казанышлары да бар. Илгиз Мисбахович моңа матур мисал да китерде.

– 3нче ЦДНГның нефть чыгару операторы Алмаз Мостафин төрле ярышларда җиңеп тора, “Татнефть” ААҖ Спартакиадасы призеры, көрәш буенча Россия чемпионатында ике тапкыр көмеш медаль яулады, – диде ул.



РӨСТӘМ МӨХӘММӘДИЕВ ВЛАДИМИР АБРАМОВКА ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕН ТАПШЫРДЫ

Төп күрсәткечләр һәм казанышлар белән таныштырып, НГДУ җитәкчесе агымдагы елга бурычларга да тукталды. Шуларның берсе – нефтьне 2559 мең тонна күләмендә чыгаруга ирешү, шуның 445 мең тоннасы Ашалчы чыганагындагы югары үзлелектәге нефть булыр дип күздә тотыла.

– Агымдагы елда безгә бурычларны ресурсларны кырыс экономияләү шартларында үтәргә туры килә, бу һәм финанс, һәм матди якка да кагыла. Коллективыбызның мондый бурычны үтәячәгенә иманым камил, – дип нәтиҗә ясады Илгиз Салихов.

Башка докладчыларны да тыңлагач, конференциядә катнашучылар “Татнефть” ААҖнең йомгаклау конференциясенә делегатлар сайладылар, ул гыйнвар азагында булачак.

Идарәнең йомгаклау конференциясендә чакырылган кунаклар да катнашты. “Татнефть” ААҖ генераль директорының кадрлар һәм социаль үсеш буенча урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев компаниянең узган елдагы эшчәнлеге белән таныштырды һәм елның начар узмавын билгеләп үтте. Ә “Нурлатнефть” НГДУсының нәтиҗәләрен яхшы дип атады, коллективның эшен уңай бәяләде. Оешманың профком рәисе Гомәр Яруллин да шул фикердә иде, ул конференция башланыр алдыннан эш урыннарында булып чыкты. “Барысы да стандартларга туры килә”, – дип билгеләп үтте ул.

Нефтьчеләр эшенең мөһимлеген, аларның шәһәр һәм район үсешенә керткән өлешен район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин да ассызыклап узды. Әнә, “Татнефть” бүлеп биргән 25 млн. сумга узган ел шәһәрдә 10 йортның түбәсен капиталь ремонтлау мөмкин булды. Әсхәт Касыймович алга таба да нурлатлыларның нефть компаниясе ярдәменә өмет тотуларын белдерде.

НГДУ эшчәнлегендәге уңай динамика бу көнне бүләкләнүчеләрнең санында да чагылгандыр, мөгаен. Идарәнең ике хезмәткәре югары бүләккә ия булды – 1нче ЦДНГның нефть һәм газ чыгару операторы Владимир Абрамовка “Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе”, ә идарә начальнигының капиталь төзелеш буенча урынбасары Наил Мостафинга “Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе” дигән мактаулы исемнәр бирелде. Шулай ук РФ Энергетика министрлыгы бүләкләре дә тапшырылды: ЦППДның катлам басымын тоту операторы Салават Әхмәтов Мактау грамотасы, ЦКППНның сусызландыру һәм тоздан арындыру җайланмасы операторы Фазыл Гарифуллин Рәхмәт хатына ия булдылар. Баш инженер-НГДУ начальнигының беренче урынбасары Равил Әхмәдиев Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде. Шунда ук Рөстәм Мөхәммәдиев “Татнефть” ААҖнең “Иң яхшы Яңа ел чыршысы-2014” конкурсы нәтиҗәләре буенча “Нурлатнефть” НГДУсы начальнигы Илгиз Салиховка җиңүче дипломы тапшырды. Традиция буенча, “Нурлатнефть” НГДУсы уздырган объектларны Яңа елга иң яхшы бизәү конкурсында җиңгән цехлар да билгеләп үтелде.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА,**
автор фотолары

*Реклама хокукында*

ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

## Ветераннарга медальләр әзерләнә

**“Родные лица Победы” проекты кысаларында нәшер ителүче фотокитапка районның 11 Бөек Ватан сугышы ветераны керер дип планлаштырыла.**

Бу хакта республикада Җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итү чараларына әзерлеккә багышланган видеоконференциядә хәбәр иттеләр. 21 февральдән исә районда яшәүче 77 Бөек Ватан сугышы ветераны һәм инвалидларына юбилей медальләре тапшыру эше башланачак. Республикада чараның беренчесе Казанда узачак, ә аннан бүләкләр тапшыру районнарга күчә. Бөек Җиңүнең юбилеена әзерлек чорында ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы линиясе аша “Кадерле ветераныбыз” акциясе дә узачак. Бу чорда әлеге категория гражданнар 30 апрельгә кадәр диспансерлаштыру үтәргә тиеш. Район хастаханәләрендә ветераннар өчен ике кешелек, бар уңайлыклы 5 махсус палата булдырылган. Шуларның берсе - Чулпан участок хастаханәсендә, 2се ЦРБның – хирургия, тагы 2се терапия бүлекләрендә.

Юбилейга әзерлек эшләре районның һәр социаль тармагында да алып барыла. Бу уңайдан район башлыгы Равил Кузюров катнашында түгәрәк өстәл үткәрү дә планлаштырыла. Җиңү парадына әзерлек эшләре дә башланды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

## “Үлемсез полк” үсә

**Нурлатның биш дистәгә якын гаиләсе фронтовик туганнарын “Легенда” хәрби-патриотик клубының “Үлемсез полкы”на яздырган.**

Полкның беренче парадка чыгуы 9 Майда булачагын хәбәр иткән идек инде.

– Кешеләр Бөек Ватан сугышы солдатларының йөзләрен күрергә һәм хәтерләргә тиешләр, – дип саныйлар акцияне безнең шәһәрдә оештыручылар Алексей Халипа һәм Владимир Малыгин. – Әгәр шәхси архивта фронтовикның фотографиясе сакланмаган икән, аның шәхси мәгълүматлары – фамилиясе, исеме һәм әтисенең исеме белән штендер ясарга кирәк. Билгеле булганча, фронтка киткән 16 мең нурлатлының яртысы кире әйләнеп кайтмаган. Елдан-ел ветераннар сафы да сирәгәя. Аларны безнең арабыздан картлык, төзәлеп бетмәгән яралары алып китә тора. “Үлемсез полк” исә каһарманнар турында хәтер яңарту һәм аларның батырлыгы хөрмәтенә оеша да.

**Маргарита ЛИТТА**

# Каникуллар әрәмгә узмады

**ЯҢА ЕЛ КАНИКУЛЛАРЫ ЧОРЫНДА УКУЧЫ-СПОРТЧЫЛАР ӨЧЕН УНБИШЛӘП ЯРЫШ УЗДЫ**




КЫЗЛАР АРАСЫНДА ТӨП КУБОКНЫ 2НЧЕ МӘКТӘП ВОЛЕЙБОЛЧЫЛАРЫ ОТТЫ

**ВОЛЕЙБОЛ.** *Спорт каникулларын, гадәттәгечә, район башлыгы Кубогына волейбол ярышлары ачып җибәрде. Быел бу турнир бишенче тапкыр уздырылды, һәм Нурлат гимназиясендә үткән ярышлар ике көнгә сузылды. Иң элек мәйданга кызлар чыкты. Биредә шәһәрнең 2нче, 3нче, 4нче, 9нчы, гимназия, шулай ук Колбай Мораса, Иске Чаллы һәм Урта Камышлы мәктәпләре командалары көч сынашты. Турнирны ачу тантанасында район башлыгы Равил Кузюров та катнашты. Нәтиҗәдә, күчмә Кубокны быел 2нче мәктәп кызлары яулады, II урын – гимназиядә, III урында – 3нче мәктәп.*

*Үсмерләр арасында төп трофей өчен тугыз командa көч сынашты. Биредә дә шәһәр мәктәпләре һәм техникумнан тыш, Киекле, Иске Чаллы, Егоркино һәм Фома кебек авыл мәктәпләре командалары да матур уен күрсәттеләр. Турнирның җиңүчесе исеменә исә гимназия волейболчылары лаек булды. 3нче мәктәп һәм аграр техникум II-III урыннарны бүлеште.*

**"ЛЕДОК" БОЗ САРАЕНДА яңа ел башыннан ук уннан артык ярыш, тамаша оештырырга өлгерделәр.**

Биредә өч көн буе "Бәхетле билет" акциясе үтте. "Бәхетле" билет эләккәннәр бозда берәр сәгать түләүсез шуа алды. Шунда ук шуарга килүчеләр өчен "Ледок"ның медицина хезмәткәрләре кислород коктейльләре турында әңгәмәләр дә үткәрделәр. Теләүчеләргә коктейльләр дә тәкъдим ителде.

Әлбәттә, хоккей уеннары да тынып тормады. 3 гыйнварда "Ледок" бозында Киекле һәм Чулпан командалары арасында иптәшләрчә очрашу үтте, биредә 3:0 исәбе белән киеклеләр отты. "Ледок"ның 2000 елгы үсмерләр арасындагы командасы Самараның ЦСК ВВСы белән иптәшләрчә матч уздырды һәм 5:4 исәбе белән җиңүгә иреште. Хоккей буенча Россия беренчелегендә чираттагы тур кысаларында "Ледок" Йошкар-Оланың "Спартагы" белән көч сынашты. Кызганычка каршы, хуҗалар ике уенда да оттырырга мәҗбүр булдылар. Моннан тыш, 2007 елгы яшь хоккейчылар өчен "Күңелле стартлар" оештырылды. Балалар "Ух!" һәм "Эх!" командаларына бүленеп, төрле сынаулар үттеләр. Яшь хоккейчылар өчен күрсәтелгән "Ак Барс. Победная феерия" фильмы да балаларда зур кызыксыну уятты.

Яшь акробатлар да тик ятмады. Мисал өчен, Эльвина Вәлиевада шөгыльләнүче яшь фигурачылар әти-әниләре өчен күрсәтмә чыгышлар тәкъдим иттеләр. Ксения Пайрамова секциясенә йөрүче инде 3 һәм "Яшь фигурачы" разрядына ия 40лап спортчының чыгышларын да ата-аналар сокланып күзәтте. Фигуралы шуу бүлегендә хореография буенча ярышларда 6-12 яшьлек балалар көч сынашты. Алар беренче яртыеллык программасында өйрәнгән төрле элементлар күрсәттеләр.

Үзләренә хас булганча, "Ледок" спорт сарае игелекле гамәлләр турында да онытмады. Мәсәлән, 9-10 гыйнварда "Раштуа очрашулары" дип аталган чара кысаларында күпбалалы һәм аз керемле гаиләләрдәге балалар өчен түләүсез шуулар оештырылды. Ә 11 гыйнвар көнне "Ледок" хезмәткәрләре Бөек Ватан сугышы ветераны Агриппина Сидорованы туган көне белән котладылар.

**Илназ МӨБАРӘКШИН**

**БИЛБАУ КӨРӘШЕ.** Чулпан авылында үткән билбау көрәше буенча Нурлат районының ачык беренчелегендә хуҗалар – Нурлат районыннан тыш, Тукай, Лаеш, Әлки, Аксубай, Алексеевск, шулай ук күрше Самара өлкәсенең Шентала һәм Кошки районнарыннан да яшь көрәшчеләр катнашты. Бу көнне келәмгә барлыгы 150ләп спортчы чыкты, шуларның 30лабы кызлар иде. Ярышларны карарга район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин һәм мәгариф бүлеге начальнигы Линар Манәпов та килделәр. Алар күптән түгел билбау көрәше буенча дөнья беренчелегендә икенче урын яулаган Чулпан егете Илнур Сәетовны котладылар. Шулай ук Чулпан егетләре Илнур Насыйбуллин белән Рөстәм Вәлиәхмәтов та аерата матур көрәш күрсәткән үсмерләргә үз бүләкләрен тапшырдылар. Беренчелектә исә призлы урыннарның күпчелеген Нурлат районы көрәшчеләре яулады.

**МИЛЛИ КӨРӘШ.** Балалар-үсмерләр спорт мәктәбендә милли көрәш буенча традицион районара турнирга быел да, гадәттәгечә, Аксубай һәм Әлки районнарыннан яшь көрәшчеләр килде. Нурлат өчен ДЮСШның үзендә һәм спорт мәктәбенең "Нурлатнефть" НГДУсында, Иглай, Югары Нурлат, Чулпан, Түбән Нурлаттагы филиалларында шөгыльләнүче үсмерләр чыгыш ясады. Бу көнне келәмгә исә 100дән артык яшь көрәшче чыкты.

**МИНИ-ФУТБОЛ.** Спорт мәктәбендә тарихи турнир үтте: биредә беренче тапкыр данлыклы футболчы-якташыбыз Галимҗан Хөсәенов истәлегенә мини-футбол ярышлары уздырылды. Әлеге турнир мәктәпләр арасында үтте, анда кече һәм урта яшьтәге төркемнәрдә барлыгы унбиш команда көч сынашты. Нәтиҗәдә, 2002-2003 елгы яшь футболчылар арасында беренче урынны 2нче мәктәп яулады. 1нче мәктәп һәм гимназия II-III урыннарны бүлештеләр. 2000-2001 елгы уртанчы төркемнәр арасында 9нчы мәктәп җиңүче булды. II урында – гимназия, IIIдә – 2нче мәктәп. Шунысы игътибарга лаек, уртанчы төркемдә җиңүче исеме өчен 9 команда көч сынашты. Биредә Иглай һәм Егоркино авыллары мәктәпләреннән килгән яшь футболчылар да лаеклы көндәшлек күрсәтә алдылар.

**ГЕР СПОРТЫ.** Нурлат егете Илнур Кәлимуллин күптән түгел гер спорты буенча Казан шәһәренең ачык беренчелегендә III урын алуга иреште. Ул 85 кг.га кадәрге үлчәү категориясендә чыгыш ясап, двоеборье суммасы буенча 195 килограмм күтәргән. Заманында Нурлатның 2нче мәктәбен тәмамлаган Илнур бүген республиканың Экология министрлыгында эшли, ә башкала чемпионатында ул Нурлат исеменнән чыгыш ясаган.

**ЧАҢГЫ СПОРТЫ.** Нурлат укучыларының җыелма командасы "Президент спорт уеннары" Бөтенроссия ярышларының зона этабында җиңү яулады. Әлеге ярышлар Лениногорск шәһәрендә узды һәм анда унга якын команда катнашты. Нәтиҗәдә, Дарья Белова һәм Виталий Кашкаров – I, Максим Панков – II, Юлия Григорьева III урыннар алып, Нурлат командасының җиңүенә зур өлеш кerttеләр. Команданың тренеры – Иван Белов. Бүген әлеге чаңгычылар "Президент спорт уеннары"ның Казанда узачак финал этабына әзерләнә.

**МӘКТӘПЛӘРДӘГЕ ЯРЫШЛАР.** Бу чорда мәктәпләрдә дә ярышлар тынып тормады.

– Без кизләүлеләр белән хоккей буенча иптәшләрчә очрашу уздырдык, – ди Фома мәктәбе директоры Хәлим Сафиуллин. – Командабыз оттырды, әмма, җиңү үзмаксат түгел иде, укучылар бер-берләре белән якыннанрак аралашсыннар, дуслашсыннар дип оештырдык бу чараны. Очрашу үзе дә "Дуслык" исеме астында үтте. Соңыннан кунакларга мәктәбебезнең музеен да күрсәттек.

Шәһәрнең 9нчы мәктәбендә "Яңа ел күңел ачулары" оештырылды. Биредә һәркем өчен дә шөгыль табылды. Укучылар директор Гаяз Таҗиев һәм физкультура укытучысы Алексей Тихонов белән бергәләп чаңгыда шудылар. Мәктәптә шашка турниры гөрләде. Диләрә Хәсәншина "Яңа ел сюрпризы" дигән мастер-класс күрсәтте, анда теләкләре булганнар үз куллары белән стена сәгате ясый алдылар. "Легоконструирование" түгәрәге җитәкчесе Наталья Созонова булачак дизайнерлар һәм конструкторлар өчен кызыклы занятие уздырды. Иң кече спортчылар "Күңелле стартлар"да көч сынашты. Аннан барысы бергәләп "Раштуа утырмалары"нда күңел ачтылар. Р. Лучкова җитәкләгән "Креатив" түгәрәгенә йөрүче балалар бик кызыклы Раштуа тамашасы әзерләгәннәр иде. Бәйрәм яңа ел дискотекасы белән тәгәлләнде.

*Гомумән, оештыручыларның сүзләренә караганда, ун көн эчендәге төрле ярышларда һәм чараларда 1000нән артык укучы катнашкан.*

**Илназ МӨБАРӘКШИН**




СУПЕРПРИЗ ИЯСЕ – МИДХӘТ РӘГЫЙБШИН

ПРИЗ СЕКТОРЫ

## Истәлеккә – иттарткыч, блендер, үтүк...

**16 гыйнварда "Дуслык" район газетасы узган ел азагында игълан ителгән зур призлы декаданың нәтиҗәләре буенча бүләк откан әбунәчеләребез белән очрашты.**

Җырчы Фирдүс Тәмаевтан суперприз-мультифункцияле иттарткыч Чулпан авылында яшәүче газета укучыбыз Мидхәт Рәгыйбшинга насыйп булган.

– Гомеремдә беренче тапкыр мондый зур бүләк отам, - ди Мидхәт ага бүләккә сөенеп. – Дөрес, Яңа ел лотереяларында призлар откалаган бар иде үзе. Иттарткыч без, өлкәннәр өчен менә дигән бүләк. Рәхмәт мондый акцияләр оештыруыгызга. Районканы бик күптән, "Октябрь колхозчысы" исеме белән чыккан вакыттан бирле яздырабыз. Барлык кирәкле мәгълүмат бар.

Нурлатлы Роза Лаврентьева да районкага призлы ункөнлек эчендә язылган икән.

- Әбунә кампаниясе барышында төрле кызыктыргыч моментлар булды. Баштарак альтернатив вариантны сайлаган идем, соңыннан почтальон аша алдырырга булдым. Бик шәп бүләк – блендер оттым. Өлкән яшьтә булсам да, газетаның хәрефен дә калдырмыйча укыйм. Район, республика үзгәрешләрен шуннан беләм.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ГАДӘТТӘН ТЫШ

## Үги әтисенә аткан

**Гыйнвар башында Нурлаттагы бер гаиләдә низаг чыга.**

Гаилә башлыгы 7 гыйнварда шактый гына салмыш көе аудан кайта, хатыны белән бәхәс килеп туа. Хәләл җефетенең шелтә-үпкәләре аучыга ошамый, ул хатынны буа башлый. Үги әтисенең әнисен буганын 17 яшьлек егет тә тыныч кына карап тора алмый, ул травматик пистолет ала да, теге ир-атның башына ата. Бәхеткә, тегесе кечкенә яралар белән генә котыла.

**Валентина ВАФИНА**

# ТӨРЛЕ. БЕЛДЕРҮЛӘР

ХӘТЕР. ХАТИРӘ

## Габбас Гыйматдинов истәлегенә



ГАББАС ГЫЙМАТДИНОВ ҮЗ КОМАНДАСЫНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕ БЕЛӘН КИҢӘШМӘДӘН СОҢ

Габбас Кыям улы Гыйматдинов белән мин 1969 елның көзендә таныштым, мине станция начальнигы итеп билгеләгәннәр иде. Ульян бүлеге начальнигы В.Бирсанов белән без аңа кабул итүгә килдек. Миңа карагач, Габбас Кыямович: шундый җаваплы урында эшләргә көчең җитәрме икән? – дип сорады. Минем энергиям җитәрлек, дип җавап бирдем. Аннан КПСС әгъзасы булу-булмавым белән кызыксынды һәм партиягә керергә тәкъдим итте. 1970 елның июнендә ул шәхсән үзе миңа партия билетын тапшырды, мин аны хәзер дә саклыйм. Партия-хуҗалык активының бер киңәшмәсендә ул районны үстерү мәсьәләсе белән чыгыш ясады, авылларны үстерүгә, күперләр, юллар, шәһәр урамнарын, торак төзүгә игътибар юнәлтте, район үсеше өчен барлык мөһим мәсьәләләрне күтәрде һәм йөкләнгән участок өчен җитәкчеләр җавап тотачак, дип тә кисәтте. Адлер Газизуллинны район башкарма комитеты рәисе урынбасары итеп билгеләде һәм аңа күперләр, юллар төзелешен йөкләде. Нурлатта нефть тармагын үстерү башланды, берүк вакытта станция дә төзелде, кабул итү-озату юллары, юллар төзүгә зур күләмдә инерт материаллар бушату өчен килү юллары артты. Габбас Кыямович, Урал, Башкортостан һәм Ульян өлкәсеннән йөкләр алып кайту өчен "вертушкалар" булдыру мәсьәләсен хәл итү ер юллары начальнигы Геннадий Черновны чакырырга тәкъдим итте. Барлык мәсьәләләр дә уңай хәл ителде. Моннан тыш, Башкорт бүлекчәсенең Дема станциясендә планлаштырылган йөк дворы төзелеше безнең станциягә күчерелде. Мөлаем, зирәк акыллы Габбас Кыямович кырыс, әмма шул ук вакытта кешелекле дә җитәкче иде, һәрвакытта да үз командасында эшләүчеләрнең тормышы белән кызыксынды, берәр мохтаҗлык булса, ярдәм итте. Мин аның белән ул лаеклы ялга чыккан көнгә кадәр эшләдем. Шул чор эчендә юллар да, күперләр дә, торак та төзелде, авыллар үзгәрде, станция 4 класслыдан 1нчегә кадәр үсте. Миңа Мария Михайловна Спасова белән ике тапкыр өлкә партия конференциясе делегаты булу бәхете дә эләкте, һәм делегациябезне КПССның өлкә комитеты җитәкчеленә тәкъдим иткәндә, безне Гыйматдинов лачыннары дип атадылар. Без районыбыз һәм үзебезнең данлыклы командирыбыз өчен чиксез горурлык хисләре кичердек. Табигатьтән килгән тыйнаклыгы, партия этикасын төгәл аңлавы, анык гражданлык позициясе булуы белән Габбас Кыям улы Гыйматдинов Октябрь, ә хәзер Нурлат районы халкының тирән хөрмәтен яулады. Аның һәм Габбас Кыямович белән бергәләп районны аякка бастыручы башка ветераннар турындагы хатирәләрне бер генә буыныбыз да онытырга тиеш түгел.

**Любовь ГАЗИЗУЛЛИНА,**
СССРның Мактаулы тимер юлчысы,
Нурлат шәһәренең Мактаулы гражданины


**ИГЪТИБАР!**

**Алексеевск кирпеч заводы керамик кирпеч сата.**

**Китереп бирәбез.**

**8-937-527-62-62, 8-927-677-36-25, 8(84341) 2-66-83.**


Список избирательных участков местного референдума 10 марта 2015г. на территории Елаурского сельского поселения:

Елаурский избирательный участок №2378.

Границы: село Елаур, село Кирпичное, деревня Сосновка, поселок Петровский.

Местонахождение: МБОУ «Елаурская СОШ», ул. Центральная, д. 25, тел. 4-32-48.

Количество избирателей: 434.

Берлек-Михайловский избирательный участок №2379.

Границы: деревня Берлек-Михайловка, поселок Октябрина.

Местонахождение: Октябринский СК, ул. Садовая, д. 3, тел. 4-32-14.

Количество избирателей: 128.


**ТР ДОСААФының НУРЛАТ районара бүлеге А, В, С, Д, Е категорияле машина йөртүчеләр әзерли.**

**Заманча методикалар буенча укытабыз.**

**Кулай бәяләр.**

**Процентсыз бүлеп түләү** *(банк катнашыннан башка).*

**Нурлат, М.Х.Сәлимҗанов ур., 16.**

Сайт: ***nurlat-dosaafrt.3dn.ru***

**2-37-93, 8-927-671-17-97.**

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 16.04.2014 елда бирелгән №5484 лиц.


**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ «ТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ ТКХ БҮЛЕГЕ БАШ БЕЛГЕЧЕ» ВАКАНТЛЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ.**

**МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ ВАЗЫЙФАСЫНА ТҮБӘНДӘГЕ КВАЛИФИКАЦИОН ТАЛӘПЛӘР КУЕЛА:**

**Һөнәри белем дәрәҗәсенә карата:** *махсус урта, югары һөнәри (төзелеш буенча) белем.*

**Конкурста катнашу өчен түбәндәге документлар кирәк:** *белем турында документ, паспорт, хезмәт кенәгәсе (күчермәсе), 2 фоторәсем, медучреждение белешмәсе.*

**Документлар 20 көн дәвамында Нурлат, Совет ур., 98, 13 кабинетта урнашкан кадрлар бүлегендә кабул ителә.**

**Белешмәләр өчен т.: 2-06-19.**


**24 ГЫЙНВАРДА ЦРБ поликлиникасында**

*ТҮБӘНДӘГЕ ЮНӘЛЕШЛӘР БУЕНЧА*

*КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ МДЦ ТАБИБЛАРЫ КАБУЛ ИТӘ:*

***8:00 сәг. Эндокринология** Неврология Кардиология*

***14.00 сәг. Кан тамырлары хирургиясе** (аппаратура белән)*

**Т. 8-917-269-54-27.**

КИЛЕШМӘСКӘ МӨМКИН. БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ КИРӘК



**Нурлат аграр техникумы «А-1» категорияле а/х производствосы тракторчы-машинисты һөнәре ("водитель внедорожных мототранспортных средств") һәм «D» категорияле шоферлар әзерләү буенча түләүле курсларга гражданнар кабул итә.**

**Нурлат, Ленинград ур., 15.**

**2-48-28.**

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 13.02.14 елда бирелгән 16ЛО1 сер. №001017 №5366 лиц.



**Оешма төргәкләнгән печән, салам, шулай ук арпа сата. Китереп бирү мөмкин.**

**8-937-183-52-60.**


### КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК

*Йорт. Т. 8-919-684-40-03.

*Үзәктә фатир, 30 кв.м, 1нче кат. Т. 8-927-031-23-45.

*Ашыгыч, бүлмә, арзан. Т. 8-927-047-10-21.

*Йорт. Т. 8-937-77-40-132.

*1 бүлмәле фатир, Яшьлек мкр. Т. 8-927-670-07-25.

*Җиңү ур.да йорт. Т. 8-927-405-51-82.

*Үзәктә 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-435-98-20.

*2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-493-21-89.

*Ленин ур., 45тә бүлмә. Т. 8-937-524-94-36.

### АВТОТРАНСПОРТ

*«ВАЗ-21099», 2001 елгы. Бәясе килешү буенча. Т. 8-927-422-17-70.

*«ГАЗель», 7 урынлы, тоташ тимердән, 2011 елгы, бик яхшы, 90000 км йөргән, бәясен килешербез. Т. 8-937-776-59-18.

*«ВАЗ-2199», көмешсыман-чия төсендә, карбюраторлы, йөреп тора, 2000 елгы, 45000 сум. Сатулашу урынлы. Т. 8-927-247-67-08.

*«Шевроле Авео», 2010 елгы. Т. 8-927-455-44-98.

*«ВАЗ-2115», 2007 елгы. Т. 8-927-248-26-04.

*«ВАЗ-21074», 2002 елгы, шәмәхә; «Форд Фокус2», 2010 елгы, кара, бик яхшы. Т. 8-927-474-03-22.

*«Джилли МК», 2010 елгы, 25000 км йөргән. Бәясен килешербез. Т. 8-917-886-57-85.

*«Ока», 2005 елгы, 30000 сум. Т. 8-917-938-62-58.

*«Лада Гранта», 2012 елгы, ак. Т. 8-937-281-37-21.

### БАШКАЛАР

*ПГС, ком, елга ташы, вак таш, керамзит. Т. 8-927-401-51-91.

*Үгез бозаулар, китерәбез. Т. 8-927-870-49-62.

*Какланган казлар, түшкәләр, эч-башлары. Т. 8-929-726-57-63.

*Какланган казлар һәм түшкәләр. Т.: 8-937-588-27-15, 8-960-033-23-77.

*8 айлык үгез бозау. Т. 8-927-245-32-03.

*Бала арбасы-трансформер: люлька, урамда йөри торган, машинага кәнәфи. Бәяләрен килешербез. Т. 8-937-004-95-48.

*Бәрәннәре белән сарыклар (60 баш). Т. 8-937-777-27-01.

*Кәрәз (Ульяннныкы), 400 сум/кг. Т. 8-927-751-61-46.

*Удмуртиядән теләсә нинди катлаулылыктагы буралар, идән, түшәм, бәпкәләр белән комплектланганнары һәм комплектсызлары да бар; төрле үлчәмнәрдәге өйләр һәм мунчалар. Т. 8-987-008-60-31.

*Сыер, февральдә бозаулыйсы. Т. 8-927-404-88-81.

*11 айлык тана. Т. 8-927-419-89-28.

*Төргәктә био-туалет, арзан. Т. 2-87-04.

*Йомшак җиһаз, кыйммәт түгел. Т. 8-927-673-75-80.

*Шифоньер, ике карават, комод, кыйммәт түгел. Т. 8-927-404-69-16.

*ПГС, ком, елга ташы, жом. Т.: 8-927-402-13-40.

*Ходунки (инвалидларныкы). Т. 8-927-672-06-04.

*Утын. Т. 8-937-617-11-21.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

***Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.**

***Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.**

*Сыйфатлы ремонт. Т. 8-937-773-98-04.

*Такси: Нурлат-Самара. Көн саен. Өегездән килеп алам. Т. 8-927-673-79-46.

*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.

*Өегезгә килеп суыткычлар төзәтәм. Т. 8-927-419-56-48.

*Ишекләр, йозаклар кую; плитка, пластик һ.б. Т. 8-937-620-01-70.

*Юрист хезмәтләре: ДТПның иминият түләвен алу. Т. 8-927-415-01-51.

*Теләсә нинди катлаулылыктагы гипсокартон конструкцияләр, армстронгтан офис түшәмнәре, кыйммәт түгел. Т. 8-937-611-40-69 (Дмитрий).

*Компьютерыгызга ярдәм. Т. 8-909-308-22-56.

*Йөк күчерү. Т. 8-929-721-37-65.

### РӘХМӘТЕБЕЗ ЧИКСЕЗ

6 гыйнвар көнне кадерле әниебез **Хәдичә Нургали кызы Вәлиуллина** вафат булды.

Кайгыбызны уртаклашкан туганнарыбызга, күршеләребезгә, Кизләү мәктәбе хезмәткәрләренә, авылдашларыбызга, сыйныфташларыбызга, дусларыбызга бик зур рәхмәтебезне белдерәбез.

**Кизләүдән кызлары, кияүләре, оныклары.**

*Суыткычлар төзәтәм. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.

*Фатирларга ремонт. Т. 8-927-446-99-98.

*Кар көрибез. Т. 8-927-244-84-71.

*Видеокүзәтү. Т. 8-927-408-70-37.

*Электр чыбыкларын, үткәргечләрне алыштырабыз. Т. 8-937-299-97-88.

*56-60 яшьләрдәге начар гадәтләре һәм торыр урыны булмаган хатын-кыз белән танышырга телим. Т. 8-927-400-37-36.

*Кер юу машиналары һәм су җылыткычлар төзәтәм. Т.: 8-927-468-16-31, 8-917-926-34-78.

*«ГородСтрой» ОООсы заказчының үз проекты буенча шәхси торак йортлар төзүгә заказлар кабул итә. Т.: 2-85-45, 2-85-22, 8-927-423-72-22.

### АЛМАШТЫРЫЛА

* Торак йортны – 1 бүлмәле (өстәмә түләп) яки 2 бүлмәле фатирга. Т. 8-987-229-46-88.

### КИРӘК

*1 бүлмәле фатир. Т. 8-937-573-05-78.

*Казанда фатир. Т. 8-937-525-20-02.

*Тәҗрибәле җиһаз җыючы. Т. 8-927-406-96-56.

*Оешмага даими эшкә ПОС монтажлау һәм хезмәт күрсәтү буенча белгечләр. Т.: 2-92-03, 8-919-636-70-17.

*«Сөләйманов Ә.И.» КФХсына машина белән саву операторлары. Т.: 3-95-20, 3-95-03.

*«Спецэнергомонтаж»га электр һәм газ белән эретеп ябыштыручылар. Завод тыкрыгы, 1а (ЖБИ). Т. 2-60-75.

*«Услуга» ОООсына медицина белеменә ия массаж ясаучы. Т.: 2-43-04, 2-43-03.

### САТЫП АЛАМ

***Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.**

*210 сумнан мөгезле эре терлек ите. Т. 8-937-804-50-24.

*Мөгезле эре терлек, ат. Т. 8-927-481-30-38.

*Мөгезле эре терлек тиреләре, кыйммәткә. Т. 8-937-281-75-63.

*Мөгезле эре терлек, кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.

*Үзәктән 3 бүлмәле фатир. Т. 8-927-435-98-20.

*Карбюраторлы двигатель («ВАЗ-2106»). Т. 2-33-87.

*Көнчыгыш яки Төньяк-Көнчыгыш мкр.дан участок (фундамент белән дә ярый). Т. 8-927-405-45-80.

*Мөгезле эре терлек, атлар. Т. 8-927-402-08-51.

### БИРЕП ТОРЫЛА

*Үзәктән тәүлекләп фатир, чеклар. Т. 8-929-727-47-80.

*Тәүлекләп фатир. Т. 8-927-406-11-06.

*Тәүлекләп 1, 2 бүлмәле фатирлар. Т. 8-927-456-59-10.

*Тәүлекләп фатир. Т. 8-927-448-33-48.

*Тәүлекләп фатир. Т. 8-937-577-51-24.

*Командировкадагыларга сәгатьләп, тәүлекләп фатир. Т.: 8-927-456-05-69, 8-927-402-35-86.

*Барлык уңайлыклары булган 2 бүлмәле фатир. Т.: 8-917-938-14-20, 8(84344) 4-05-52.

*Чишмә авылында читтән килеп эшләүчеләргә йорт. Т. 8-927-726-01-45.

### ЮГАЛТУЛАР

*«Рено» документларын табучының аларны кайтарып бирүен сорыйм. Буш итмәм. Т. 8-937-616-47-27.

*Юрий Иванович Иштуллин исеменә паспортны кайтарып бирүегезне сорыйм. Т. 8-937-528-81-61.